РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 03 » 11 2021 г. № 903

Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2025 елларга «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 11 ноябрендә кабул ителгән 865 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру турында» 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасы нигезендә, «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү” дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2025 елларга «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 11 ноябрендәге 865 номерлы карарында, 1 нче кушымтага, 34 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Сатып алына торган торак (шул исәптән өлешләп төзү объекты булып торганы да) Татарстан Республикасы территориясендә булырга яки төзелеш Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә ашырылырга тиеш».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе С. П. Самонина

Н.А. Абильтарова
2-76-81